ТАТАРСТАН  РЕСПУБЛИКАСЫ АПАСТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОШТАУЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

10 марта 2023 ел №109

Коштаулы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 31 пункты, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Коштаулы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Коштаулы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының 2016 елның 15 апрелендәге 27 номерлы карары белән расланган Коштаулы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын мөмкин булган бозу фактлары турында мәгълүматны үз эченә алган язма мөрәҗәгать, әлеге Нигезләмәнең 4.9 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш, федераль башкарма хакимият органының территориаль органына һәм Татарстан Республикасы башлыгына (Рәисенә) теркәлгәннән соң биш көн эчендә юллана.»

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (бастырып чыгарырга)

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Коштаулы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Коштаулы авыл җирлеге Башлыгы,
Коштаулыавыл җирлеге Совет рәисе Х.Ф.Сабиров